ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.11.2019 г. Заинск № 594

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 14 апрелендәге 674 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» 2014 елның 07 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру, карарларны әзерләү һәм кабул итү өлешендә муниципаль идарә процессларының нәтиҗәлелеген һәм аларны камилләштерүне арттыру максатларында Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитеты

**карар бирә:**

1.Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 14 апрелендәге «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында нигезләмәне раслау хакында» 674 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль районы муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы

башкарма комитетының 2019 елның 29 октябрендәге 566 номерлы карары белән кертелгән үзгәреш белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2 Җайга салу йогынтысын бәяләүдә профильле бүлек тарафыннан акт проектын кабул итүнең максатка ярашсызлыгы турында нәтиҗә ясалган яисә аны эшләп бетерү буенча тәкъдимнәр бирелгән очракта, әзерләүче 15 календарь көннән дә соңга калмыйча аларны төзәтергә тиеш.

Акт проекты һәм норматив хокукый акт буенча тискәре бәяләмә нәтиҗәсендә каршылыклы фикерләр туганда, профильле бүлекчә 10 календарь көннән дә соңга калмыйча киңәшмә җыя.

Каршылыкларны хәл итү өчен кызыксынган затлар катнашында башкарма комитет җитәкчесе катнашында киңәшмәдә үткәрелә, анда ахыргы карар кабул ителә. Кабул ителә торган барлык карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Каршылыкларны хәл итү буенча кабул ителгән карарны үтәү профильле һәм вәкаләтле бүлек өчен мәҗбүри булып тора һәм беркетмәдә күрсәтелгән срокта үтәлергә тиеш.».

2. Әлеге карар рәсми төстә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru/ рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасары М.И. Захаровага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Юрист
А.Н. Симашева
8(85558) 3 41 33